| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КРЫНДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КЫРЫНДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.07.2022 Крынды авылы № 11

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Крынды авыл җирлеге Башкарма комитетының ««2015-2030 елларга «Крынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү» муниципаль озак сроклы максатчан программасын раслау турында»» 2015 елның 12 декабрындагы 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокурорының 2022 елның 24 июнендәге 02-01-02-2022 номерлы «Ачыкланган коррупциоген факторларны булдырмау максатында норматив хокукый актны үзгәртү турында» таләпләрен үтәү йөзеннән, муниципаль хокукый актны норматив хокукый актлар таләпләренә туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Крынды авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Крынды авыл җирлеге Башкарма комитетының ««2015-2030 елларга «Крынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү» муниципаль озак сроклы максатчан программасын раслау турында»» 2015 елның 12 декабрындагы 10 номерлы карарына кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарны Крынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе А.А.Нафиков

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Крынды авыл җирлеге
Башкарма комитетының
07.07.2022 № 11
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Крынды авыл җирлеге Башкарма комитетының ««2015-2030 елларга «Крынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү» муниципаль озак сроклы максатчан программасын раслау турында»» 2015 елның 12 декабрындагы 10 номерлы карарына үзгәрешләр**

Статья 1
Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Крынды авыл җирлеге Башкарма комитетының ««2015-2030 елларга «Крынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү» муниципаль озак сроклы максатчан программасын раслау турында»» 2015 елның 12 декабрындагы 10 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.1 өлешнең 1.2 пунктының дүртенче абзацында:
«кабул ителергә мөмкин» сүзләрен «кулланыла,» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 өлешнең бишенче абзацында:
«яңадан каралырга мөмкин» сүзләрен «яңадан карала» сүзләренә алмаштырырга.